Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XXIX-3**

Балык Бистәсе штп. 2018 елның 19 феврале

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2017 елның 21 ноябрендәге XXIII-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе, “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны даими оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль закон, “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны даими оештыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2017 елның 29 декабрендәге 480-ФЗ номерлы Федераль закон, “Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар һәм багажны даими йөртүне оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында” Федераль законны гамәлгә ашыру турында” 2015 елның 26 декабрендәге 107-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының 2017 елның 21 ноябрендәге XXIII-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“8. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә даими пассажирлар йөртү (ташу) муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, гамәлдән чыгару тәртибе (шул исәптән юридик затларның,

шәхси эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның әлеге маршрутларны билгеләү, үзгәртү яки гамәлдән чыгару турындагы гаризаларын карау тәртибе, шулай ук әлеге маршрутларны билгеләүдән яисә үзгәртүдән баш тарту нигезләре, әлеге маршрутларны гамәлдән чыгару өчен нигезләр) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән билгеләнә.”;

1.2) 17 пункттагы “тиешле контрактны үтәү өчен кирәкле транспорт чараларының максималь саны нигезендә” сүзләрен төшереп калдырырга;

1.3) 19 пунктында “билгели” сүзен “билгеләргә хаклы” сүзләренә алмаштырырга;

1.421 һәм 22 пунктларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

“21. Даими пассажирлар йөртү муниципаль маршрут картасы тиешле маршрут буенча даими пассажирлар йөртү өчен файдаланыла торган һәр транспорт чарасы өчен бирелә.

22. Көйләнми торган тарифлар буенча даими пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы юридик затларга, шәхси эшкуарларга, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларга карата таләпләр, зарурлык булганда, Федераль законның 17 маддәсендәге 4 өлешен һәм Татарстан Республикасы Законының 4 маддәсендәге 7.1 пунктын исәпкә алып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының муниципаль хокукый акты белән эшләнә һәм раслана.”;

1.5) түбәндәге эчтәлектәге 22.1 пунктын өстәргә:

“22.1. Әлеге Тәртипнең 22 пунктында каралган таләпләрне бозу турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.”;

1.6) 25 пунктның 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1) Федераль законның 24 маддәсендәге 10 өлешендә яисә 29 маддәсендәге 1 өлешенең 1, 2 яки 7 пунктында каралган шартлар җиткәннән соң һәм ачык конкурс нәтиҗәләре буенча бирелгән даими пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турындагы яңа таныклык нигезендә даими пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыра башлаганчы. Федераль законның 24 маддәсендәге 10 өлешендә каралган шартлар буенча, узмаган дип танылган ачык конкурста җиңүчегә даими рәвештә пассажирлар йөртү маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм әлеге маршрут карталарын бирү рөхсәт ителми;”;

1.7) түбәндәге эчтәлекле 25.1 пунктын өстәргә:

“25.1. Юридик зат, шәхси эшкуар, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар, аларга даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыклар һәм тиешле маршрутлар карталары ачык конкурс үткәрмичә генә бирелә шул очракларда, әгәр әлеге Тәртипнең 25 пунктында каралган тәртиптә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнсә.”;

1.8) 26 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“26. Ачык конкурс үткәрмичә, даими пассажирлар ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм даими пассажирлар йөртү маршруты картасы бирү өчен нигез булып торган шартлар җиткән көнне бер тапкыр йөз сиксән көннән артып китәргә мөмкин булмаган вакытка бирелә, ә элеге маршрут буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында элегрәк бирелгән таныклыкның гамәлдә булуын туктатып тору очрагы булса, күрсәтелгән таныклыкның гамәлдә булуын туктатып тору срогына.”;

1.9) 28 нче пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

“1) Федераль законның 37 маддәсендәге 2 өлешендә каралган срокларда юридик зат, шәхси эшкуар, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучы вәкаләтле вәкил тарафыннан бер ел дәвамында берничә тапкыр даими пассажирлар йөртү маршруты буенча даими пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында квартал саен хисапларны тапшырмау;”;

2 пунктчада “3 – 5 өлешләрендә” сүзләрен “4 һәм 5 өлешләрдә” сүзләренә алмаштырырга;

1.10) 30 нчы пунктта “,автомобиль транспортында пассажирлар ташу буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыруга лицензиянең гамәлдә булуын туктатып тору очрагында туктатыла” сүзләрен “юридик затка, шәхси эшкуарга, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларга юридик затның, шәхси эшкуарның, гади ширкәттә катнашучыларның берсенең генә булса да, автомобиль транспортында пассажирлар йөртү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе булган гамәлләре туктатылган очракта, туктатыла.” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе
урынбасары И.Г.Ибраһимов